## ЯКЫН ДУСЛАР ҺӘМ ТУГАННАР

Илдар Шәрипов көе

Беркемнең дә башкаена
Кайгы-хәсрәт төшмәсен,
Ялгызлыкның ачылары
Җанкайларын телмәсен.

*Кушымта:*
Якын дуслар һәм туганнар
Булсын табын түрендә,
Җырлап-биеп, уйнап-көлеп,
Узсын безнең гомерләр!

Кәефең бар, эшең уңа,
Янда булса дусларың,
Синең өчен янып торган
Җан аткан туганнарың.

*Кушымта.*

Якын дустан һәм туганнан
Ходай мәхрүм итмәсен.
Сез бит гомеремдә - зур куаныч,
Сез бит - дөньям тоткасы.

*Кушымта.*